ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.01.2024 с.Старое Дрожжаное № 4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халык дружиналарының район штабын төзү турындагы карарга үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Чүпрәле районы прокурорының 2024 елның 9 гыйнварындагы 02-02-02-2024 номерлы протестын исәпкә алып, Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы халык дружиналарының район штабын төзү турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 2 сентябрендәге 349/1 номерлы карары преамбуласына ««Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2005 елның 1 ноябрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 2 августындагы 398 номерлы карары белән»» сүзләрен ««Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары төзүнең тәкъдим ителә торган критерийларын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 30 маендагы 388 номерлы карары белән»» сүзләренә алмаштырып, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов